Васил Гарифуллин,
Казан (Идел буе) федераль университетының
гаммәви коммуникация бүлеге мөдире,
филология фәннәре докторы, профессор,
Татарстанның атказанган фән эшлеклесе

# ОЛЫ ЮБИЛЕЙНЫҢ КЕЧКЕНӘ КАЙТАВАЗЫ

## ТАТАР ЖУРНАЛИСТИКАСЫНЫҢ 110 ЕЛЛЫГЫ: КАЗАНЫШЛАР ҺӘМ ЮГАЛТУЛАР

Моннан нәкъ 110 ел элек, 1905 елның 2 сентябрендә Санкт-Петербургта “Нур” исеме астында татарның беренче газетасы чыга башлаган. Димәк, юбилей елыбыз!

Шулай да татар вакытлы матбугатының тарихын бер гасыр яки 110 ел эченә генә сыйдырып бетереп булмый. Казан император университетының физика-математика разряды профессоры Иван Ипатович.Запольский рус һәм татар телләрендә газета чыгарырга рөхсәт сорап, 1808 елда, ягъни, моннан 207 ел элек үк, патша хәзрәтләренә мөрәҗәгать иткән булган. Андый рөхсәт хәтта алынган да. Әмма 1810 елда И.И.Запольский кинәт үлеп киткәнлектән, «Казанские известия» газетасының татар телендәгесе чыкмый кала, 1811 елдан аның русча варианты чыга башлый һәм ул Россиядәге иң беренче провинциаль газета буларак таныла.

Әгәр Запольский идеясе тормышка ашкан булса, без инде күптән татар журналистикасының 200 еллыгын бәйрәм иткән булыр идек!

Бу урында шуны да искәртеп үтү урынлы, XIX гасыр дәвамында рус һәм татар зыялылары күп тапкырлар, татарча газета чыгарырга рөхсәт сорап, патшага прошениеләр язалар, мондый үтенечләрнең саны гына да утыздан артып китә. Тик нәтиҗәсе булмый. Татар мәгърифәтчеләре, газета-журналлар чыгарырга рөхсәт булмагач, календарьлар һәм альманахлар чыгара башлый. Мәсәлән, атаклы мәгърифәтче Каюм Насыйри 24 ел рәттән календарьлар чыгаган. Аларны татар журналистикасының “чишмә башы” дип атарга була.

Шулай ук 1883 елдан Исмәгыйль бәк Гаспринский тарафыннан Кырымның Бакчасарай шәһәрендә уртак төрки телдә «Тәрҗеман» газетасы да чыгарылып килгән. Аны Россиядәге барлык төрки халыкларның зыялылары, шул исәптән Казан татарлары да күпләп алдыра һәм укый. Авторлар составының да күпчелек өлешен безнең татар әдипләре, мөгаллимнәре, шәкертләре тәшкил итә. Әйтик, Гаяз Исхакыйның беренче журналистик әсәрләре нәкъ менә шушы басмада урын алуы мәгълүм. Шуңа күрә дә кайбер галимнәр татар телендәге вакытлы матбугатның барлыкка килү тарихын нәкъ менә «Тәрҗеман»га бәйли.

Татарның үз матбугатына да Гаспринский кебек алдынгы карашлы дин һәм җәмәгать эшлеклеләре, беренче чиратта җәдитчелек тарафдарлары нигез салган. Бу эшкә иң беренче рөхсәтне 1905 елда Санкт-Петербург шәһәрендә ахун, ягъни гаскәриләр мулласы булып хезмәт итүче Гатаулла хәзрәт

Баязитов ала. Петербургта «Нур» газетасын чыга башлау белән, ниһаять, чын милли вакытлы матбугатыбыз дөньяга аваз салды. Бу матбугат, ярларыннан ташып чыккан көчле агым кебек, бөтен Россия территориясен басып ала. Күренекле дин эшлеклесе, мөфти Ризаэтдин Фәхретдин редакторлык иткән “Шура” журналы (ул Оренбургта нәшер ителә) заманында татар һәм төрки халыкларның әдәби һәм мәдәни тормышы үзәгенә әверелә. XX гасыр башында иң абруйлы һәм озын гомерле басмаларның берсе булып танылган “Йолдыз” газетасын шулай ук күренекле дин эшлеклесе, галим-теолог Әхмәтһади Максуди нәшер итә. Казандагы мәшһүр “Мөхәммәдия” мәдрәсәсенә нигез салган имам мөфти Галимҗан Баруди “Әд-дин вә әл-әдәп” журналын чыгара. Әлеге басма Россиядә мөселманнарның беренче махсуслашкан басмасы буларак тарихка кереп калган.

XX гасыр башында андый махсуслашкан дини басмаларның саны унга җитә. Шулай ук татарча сатирик журналларның саны да дистәдән артып китә. Башка юнәлешләрдә махсуслашкан басмалар да барлыкка килә. Мәсәлән, Самара шәһәре имамы Фатих Мортазин 1908 елда “Икътисад” журналын чыгара башлый. Әлеге журнал Россия мөселманнарының беренче икътисадый басмасы буларак танылa. Аудитория ихтыяҗларын истә тоткан мондый типологик дифференцация, ягъни тар даирә аудитория өчен газета-журналлар нәшер итү – төрки халыклардан бары тик татарларда гына булган феноменаль күренеш.

Галимнәребез әйтүенчә, 1905 елдан 1917 елга кадәрге чорда егермегә якын шәһәрдә төрле вакыт аралыкларында 120 ләп татарча газета һәм журнал нәшер ителгән. Алар шул чордагы барлык фиркаләр, төрле социаль катлаулар мәнфәгатьләрен чагылдыра алган. Безнеке кебек бай тарихлы матбугат һәм журналистика белән Россиядәге бик сирәк милләт кенә мактана ала. Ни кызганыч, без татар журналистикасының чираттагы олы юбилеен кабат университет кысаларында узган фәнни-гамәли конференция белән генә, тыйнак итеп билгеләп үттек. Башка халыкларда булса, матбугат тарихы белән бәйле мондый зур вакыйганы бөтен дөньяны шаулатып, олы тантаналар рәвешендә зурларлар иде. Әнә, XX гасыр башында күрше мордва дусларыбызның нибары бер генә газетасы булган. «Мужик» исемле рус телендә чыккан ул газетаның 1906 елда нибары 22 саны дөнья күргән. Революциягә кадәр бу милләтнең үз ана телендә матбугаты бөтенләй булмаган. Алар шул рус телле беренче газеталарының 100 еллык юбилеен дәүләткүләм билгеләп уздылар. Бу уңайдан Президентларының кереш сүзе белән саллы китап нәшер ителде. Чуаш туганнарыбыз да 1906 елда Казанда дөнья күргән «Хыпар» газетасының юбилеен Президент Указы нигезендә милли бәйрәмгә әйләндерделәр. Моңа багышланган китап та басылып чыкты. XX гасыр башында чуаш журналистикасы шул бердәнбер басма рәвешендә генә яшәгән югыйсә.

Ә без шулкадәр бай мирасыбыз белән тиешенчә горурлана, аны башка халыкларга, дөньяга күрсәтә белмибез. Бу байлыкны фәнни яктан тирәнтен өйрәнергә, киләчәк буыннар өчен туплап калдырырга тиешбез. Кызгыначыка,

әлеге чор-газета-журналларының күбесе, үз өйрәнүчеләрен көтеп, һаман да китапханәләрдә тузан җыеп ята...

Унҗиденче елгы инкыйлаб үсеп килүче татар журналистикасының да “тез астына сукты”. Бу чордагы революцион вакыйгалар матбугат учагын беркадәр дөрләтеп алса да (1917-18 елларда алтмыштан артык басма чыга), шуннан соңгы чорда юнәлешләре төрледән-төрле булган газета-журналларның күпчелеге ябылды. Алар урынына бер генә идеологиягә хезмәт итүче большевистик матбугат челтәре барлыкка килде. Күп кенә күренекле мөхәррир һәм редакторлар исә илдән китәргә мәҗбүр булдылар. Чит илләрдә татарча эмигрант басмалары баш калкытты. Аларны оештыручы үзәк фигураларның берсе булып күренекле җәмәгать эшлеклесе, язучы һәм драматург, Россиядә “Таң” һәм “Таң йолдызы” газеталарында эшләгән, “Ил” һәм “Сүз” газеталарын чыгарган мәшһүр мөхәррир Гаяз Исхаки танылa. 20 нче еллар башында ул Манчжуриядә “Милли байрак” газетасын оештырып җибәрә. Әлеге басма төрле дөнья буйлап таралган милләттәшләребеәне берләштереп торучы куәтле үзәккә әверелә. Ул 1945 елга кадәр Мукден шәһәрендә басылып килә, барлыгы 440 саны дөнья күрә. 1928 елдан 1939 елга кадәр Исхаки Берлинда «Милли юл» һәм «Яңа милли юл» журналларын нәшер итә. Әлеге басмалар Сталин режимын кискен тәнкыйть итүләре белән дөньяга танылa.

Болардан тыш Төркия, Венгрия, Германия, Польша, Кытай, Япония, Финляндия, Швеция, Румыния, АКШ кебек татар милләте шактый тупланып яши торган илләрдә, тарихның төрле чорларында ана телебездә кырыклап газета-журнал нәшер ителгән.

Бөтен Россия империясен шаулаткан татар матбугаты, аның олы шәхесләре әнә шулай таралды, сибелде. Егерменче еллар азагына большевистик идеологияне пропагандалаучы егермеләп кенә татарча басма орган калды. Башта мәҗбүриләп латин графикасына, аннары кириллицага күчерү дә матбугатыбыз үсешенә зур зыян салды.

Матбугатыбыз тарихының игътибарга лаек бер өлеше булып Бөек Ватан сугышы чоры тора. Әлеге чорда хәрби журналистика зур үсеш ала. Татар телендә 16 фронт газетасы нәшер ителә. Алар безнең Бөек Җиңүебезгә үзләренең лаеклы өлешен кертте.

Сугыштан соңгы чорда советлар илендә милли журналистиканы үстерүгә зур игътибар бирелсә дә, ул җиде дистә ел буенча, нигездә, хакимлек итүче идеологияне үткәрү чарасы буларак кына хезмәт итте.

Советлар Союзы таркалганнан соң, татар журналистикасы шактый гына сан һәм сыйфат үзгәрешләре кичерде. Россиядә XX гасыр азагында булган демократик үзгәрешләр милли журналистикабызның үсешенә аеруча шифалы йогынты ясады. Татарның мәгълүмат чаралары XX гасырның 90 елларыннан башлап чын мәгънәсендә яңадан туу чоры кичерде. Дистәләгән яңа газета һәм журналлар, FM радиостанцияләр, юлдаш телевидениесе, күп кенә Интернет-басмалар барлыкка килде. Бүген Татарстанда татар телле мәгълүмат чараларының төрле аудитория мәнфәгатьләрен канәгатьләндерә алырдай тотрыклы системасы булдырылды. Татарстаннан читтә чыгып

килүче татарча газеталар да, ә аларның саны 30 дан артык, тарихи Ватаннарыннан читтә яшәүче милләттәшләребезнең мәнфәгатьләрен яклауда, аларны берләштерүдә мөһим эш башкара. Өстәвенә Россиянең күп кенә төбәкләрендә татар телендә радиотелевизион тапшырулар да чыга башлады, татарча Интернет челтәре киң колач җәйде.

Соңгы ике дистә елда галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре, танылган журналистлар газета-журнал битләре, радио-телевидение каналлары, китап-җыентыклар аша татар халкының милли хисләре, теләк-омтылышлары турында телдән дә, язма сүз белән дә ачыграк әйтә башлады. Туксанынчы елларның беренче яртысында мәгълүмат чаралары Татарстан бәйсезлеге өчен кискен көрәш мәйданына әйләнде. Россия составында дәүләтчелегебезне торгызуның конструктив юллары тәкъдим ителде.

Яңа гасырга кергәч, татар матбугатында хосусый басмалар саны артып китте, аудиториягә аларның шактый гына кыю сүзе ишетелә башлады. Алар арасында көчле конкуренция барлыкка килде, тиражлары да күзгә күренеп арта бара. Бу уникаль күренешне өйрәнеп, хосусый газеталар чыгару тәҗрибәсен башка төр гаммәви мәгълүмат чаралары өлкәсенә тарату да максатка ярашлы булыр иде.

Яңа чорга безнең журналистика үзенең яңача үсеш юлларын эзли-эзли килеп керде. Моның сәбәпләре – идеологиянең алышынуы, гомумглобальләшү, социаль-икътисадый өлкәдәге кискен үзгәрешләр, яңа технологияләр, мәгълүматны туплау, эшкәртү һәм таратуның яңа ысуллары барлыкка килүе. Бу факторлар аеруча милли журналистика үсешендә кыенлыклар тудырды. Чөнки базар шартларында мәгълүмат чаралары финанс мөстәкыйльлегенә омтылырга, төрле юллар белән акча эшләү юлларын эзләргә мәҗбүр. Татар теле чын мәгънәсендә бизнес һәм икътисад теле дәрәҗәсенә ирешә алмаганга күрә, татарча мәгълүмат чыганаклары да югары конкурентлыкка ия була алмый. Әмма дөнья практикасында мәгълүмат базарын беренче чиратта милли мәнфәгатьләрне истә тотып җайга салу инде гадәткә кергән. Нәкъ менә шуңа күрә татар телле мәгълүмат чаралары безнең республикада дәүләт тарафыннан һәрьяклы яклау тоеп яши. Мондый яклау киләчәктә дә кирәк булачак: мәгълүмат өлкәсендәге технологик үзгәртеп корулар, шул исәптән тулаем цифрлы технологияләргә күчү, милли журналистиканың дәүләт яклавына ихтыяҗын тагын да көчәйтә генә.

Бүген Татарстан Республикасы мәгълүмати тәэмин ителеше ягыннан Россиядә иң алдынгы позицияләргә чыкты. Кызганычка, рус теллеләр белән чагыштырып карасаң, сан ягыннан да, сыйфат буенча да татар телле матбугат һәм радио-телевидение азчылыкны тәшкил итә.

Бүген безгә татар журналистикасының тарихыннан үрнәк һәм гыйбрәт алып, барлык идеологик көчләрнең, барлык социаль катламнарның мәнфәгатьләрен чагылдыра алырдай киң челтәрле милли мәгълүмат кыры булдырырга, бөек Исмәгыйль бәй Гаспралы үрнәгендә халкыбызны уртак максатлар астында берләштерә алырдай глобаль мәгълүмат чараларыбызны гамәлгә куярга вакыт.

Шуны аңлау аеруча мөһим, милли телләрдәге матбугат, шул исәптән татарча газета-журналлар, радио-телевидение, Интернет челтәре җәмгыятькә мәгълүмат җиткерү өчен генә яшәми. Аларның вазыйфасы күпкә катлаулырак та, җаваплырак та. Туган телебездәге мәгълүмат чаралары, милли культурабыз һәм ана телебезнең мөһим яшәеш өлкәсе буларак, бөтен дөньяда сибелеп яшәүче халыкларыбызны берләштерүче һәм алга таба алып баручы могҗизалы бер көч булып тора.

Журналистика үсешенең гаять бай традицияләренә ия була торып та һәм инде тарихчы-журналистлар тарафыннан шактый фәнни эш башкарылып та, республикада матбугат, радио һәм телевидениенең барлыкка килү һәм үсеш тарихын тулы һәм һәрьяклы итеп өйрәнә алганыбыз юк әле. Тулы бер гасыр эчендә дөньяның төрле почмакларында милләттәшләребезне берләштереп торган йөзләрчә матбугат органы, дистәләгән телевизион һәм радиоүзәкләр эшчәнлеге – болар тикшеренүне көтә торган материалның бер өлеше генә. Бу уңайдан Татарстан Журналистлар берлеге инициативасы белән Татарстан журналистикасы энциклопедиясен бастырып чыгару проекты зур әһәмияткә ия. Моның өчен инде шактый материал тупланган. Ләкин тикшерәсе чорлар, фәндә яктыртылмый калган өлкәләр дә күп әле. Аларны һәрьяклы өйрәнү һәм фәнни системага салу, татар журналисткасының күптомлык тарихын булдыру көнүзәк мәсьәләләрнең берсе булып кала. Татарстан Фәннәр академиясе яки университет каршында, ә бәлки бүген республикабызда гаммәви мәгълүмат чаралары белән турыдан-туры җитәкчелек итә торган «Татмедиа» агентлыгы каршындадыр, журналистика проблемаларын, шул исәптән журналистикабыз тарихын өйрәнү белән шөгыльләнә торган махсус фәнни оешма – институт яисә үзәк төзү максатка ярашлы булыр иде. Һәрхәлдә, 110 еллык матбугатыбызның үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген фәнни нигезле, объектив күзаллау өчен дәүләт заказы кирәзк!